Республика Татарстан
Совет Альметьевского
сельского поселения
Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль
районы Әлмәт авыл
җирлеге советы

РЕШЕНИЕ

КАРАР

20 сентябрь 2019 ел Әлмәт авылы № 17

**Җирле референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 п., Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Уставының11 статьясы нигезендә, Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

“I нче группа инвалидлар; ялгыз өлкән кешеләр; вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар; көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан кала, Әлмәт авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2020 елда үзара салымны 200 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

- Әлмәт авылының Ленин урамында урнашкан эчә торган су коеларын чистарту һәм төзекләндерү;
- Әлмәт авылы территориясенә урнаштыру өчен реклама щитлары, стендлар, баннерлар сатып алу;
- Әлмәт авылы Ленин урамына янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру;
- Әлмәт авылы Ленин урамындагы күперне төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу;
- Әлмәт авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, өлкәннәр көне, инвалидлар көне, 9 Май, яшьләр арасында волейбол, теннис ярышлары) үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;
- Әлмәт авылы Сабан туе территориясен электр белән тәэмин итү өчен кабель сатып алу;
- Әлмәт авылына урам яктырткычлары сатып алу;
- Әлмәт авылы территориясендә үлән чабу һәм куаклар кисү;

ӘЙЕ ЮК?».

2. Әлеге карар мәгълүмат стендларына һәм авыл җирлегенең рәсми сайтына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

Әлмәт авыл җирлеге башлыгы: Газизов Д. А.